УДК 297

*Д.З. Мәрданова*

# XIX ГАСЫРНЫҢ СОҢГЫ ЧИРЕГЕНДӘ ИДЕЛ БУЕ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ ХОКУКЫЙ ТӨШЕНЧӘЛӘРЕ ТАРИХИ СЕМАНТИКАСЫНА КАРАТА

## («иҗтиһад», «мөҗтәһид», «иҗмаг» терминнары хакында Ш. Мәрҗани һәм аның оппонентлары арасындагы бәхәс мисалында)

Экономические, политические, социальные и культурные изменения второй половины XIX века заставили мусульманских ученых искать ответы на вызовы Нового времени в рамках собственной традиции. В статье через полемику между Ш. Марджани и его оппонентов рассматривается пример переосмысления сложившихся ранее правовых и богословских понятий и представлений.

**Ключевые слова:** конец XIX века, Российская империя, Поволжье, Марджани, иджтихад, муджтахид, иджма‘, история понятий.

Телнең тарихи семантикасы яки төшенчәләр тарихы, нигездән үзгәртеп кору һәм һәм эволюция методы буларак, сәясәт белеме, фәлсәфә, социология, әдәбият белеме һәм тарих фәннәрендә файдаланыла. Төшенчәләр тарихы сәясәт белеме тикшеренүләренең ике төрле историографик юнәлештәге немец һәм инглиз (Кембридж) мәктәпләрендә барлыкка килә. Беренче юнәлешнең теоретик нигезләре «Германия иҗтимагый-сәяси теленең тарихи лексиконы» проектының җитәкчеләреннән берсе булган Р.Козеллек хезмәтләрендә формалаша. Әлеге проект кысаларында тарихи төшенчәләрне өйрәнүнең башлангычы булган «Төп тарихи төшенчәләр. Германиядә иҗтимагый-сәяси телнең тарихи сүзлеге» дип исемләнгән сигезтомлык зур хезмәт чыгарыла. Козеллек 1700 елдан алып 1970 елларны үз эченә алган иҗтимагый тарихчылар тарафыннан кулланылган катлаулы төшенчәләрнең семантик бәйләнешен ачыклый. Сүзлек мәкаләсенең нигезен теге яисә бу чор чыганаклары теле түгел, хәзерге тел тәшкил итә [Словарь..., 2014]. Тасвирланучы чынбарлыкның аерылгысыз өлеше буларак кабул ителгән сәяси теориянең телен өйрәнгән Дж. Покок һәм К. Скиннер хезмәтләре икенче юнәлешнең нигезен тәшкил итәләр. Икенче төрле әйткәндә, алар төшенчәләрне тарихи шартлар һәм контекстка бәйле булган тел аркылы өйрәнәләр. Кембридж мәктәбе юнәлеше «чынбарлык»ның барлык объектлары алар сыйфатлаган төшенчәләр ярдәмендә чагылуын искәртә. Скиннер карашынча, тарихта яңа идеяләр һәрдаим барлыкккa килеп тормый; бер темага мөрәҗәгать ителә һәм аерым бер төшенчә очраган төрле фикерләр аркылы телнең яңа-

лыгын һәм үзгәрешләрен күзәтеп була. Скиннер өчен шулай ук автор күздә тоткан интенция (автор нәрсә әйтергә теләве), яисә әлеге фикернең нинди дискурс эчендә барлыкка килүе, аның контекстуаль чолганышы мөһим булып тора [Скиннер, с. 12–74]. Икенче төрле әйткәндә, идеяне билгеләүче автор акторга – фикер уятка һәм яшәешен дәвам иткән бәхәснең, телнең агентына әйләнә. Пококка килгәндә, аның әлеге дисциплинага керткән методологик өлеше сәяси фәлсәфәнең тарихын «сәяси телләр», «идиомалар», «бәхәсләр» тарихы буларак караудан гыйбарәт [Атнашев, Велижев].

Безнең уебызча, дини әңгәмә-бәхәсләрне өйрәнгәндә, Скиннерның төшенчәләр тарихы һәм контекстуаль анализы дини традициядә яшәп килгән хокук буенча өйрәтмәләрнең үзгәрешен, аларның әйләнә-тирә иҗтимагый-мәдәни җирлек шартларына җайлашуын, адаптацияләнүен ачык күзаллауга ярдәм итә. Әлеге мәкаләдә XIX гасырның соңгы чирегендә Ш. Мәрҗани һәм аның оппонентлары арасында бәхәс уяткан «иҗтиһад», «мөҗтәһид», «иҗмаг» кебек ислам хокукы төшенчәләренең тарихи семантикасы өйрәнелә. Әлеге ракурс хокук төшенчәләре мәгънәләренең үзгәрешен һәм яңа төшенчәләрнең өстәлүен, барлыкка килүен ачыкларга мөмкинлек тудыра.

Мәкалә биш мәгънәви өлештән гыйбарәт. Беренче өлеш полемика контекстына кереш, икенче бүлек ислам хокукының төшенчәләрен тасвирлаучы кисәк булып тора. Өченче өлештә «иҗтиһад» термины һәм «иҗтиһад капкасы ябылу» мәсьәләсе күтәрелә, дүртенче кисәктә «мөҗтәһид» категориясенә карата төрле карашлар чагыла, бишенче бүлек «иҗмаг» мәсьәләсенә багышлана.

## Кереш яисә XIX гасырның соңгы утыз еллыгында Россия империясендә мөселманнар яшәешенең чынбарлыгы

XIX гасыр азагы – XX гасыр башында мөселман галимнәре арасында исламны ислах кылу идеяләре киң таралыш таба. Әлеге процесска Европа модерны нәтиҗәсендә мөселман җәмгыятендә барлыкка килгән идея кризисы этәргеч бирә. Көнбатыштан икътисади һәм иҗтимагый бәйлелектә яшәгән мөселман голямалары, М.Уотт билгеләвенчә, ислам дөньясының сәяси һәм икътисади бәйсезлеге турында төп мәсьәләләрне чишәргә тиеш булалар [Watt, p. 158; Hourani, 1983]. Мөселманнар, өстенлекләрен югалтып, «христиан» дөньясы шартларында яшәешнең яңа формаларын эзләргә мәҗбүр ителәләр. Тискәре үзгәрешләрнең барлыкка килүен галимнәр дөрес юлдан тайпылу, дингә (хокук һәм догматикага) тиешсез яңа үзгәрешләр кертелү белән бәйләп аңлаталар. Әлеге үзгәрешләрдән динне арындыру өчен реформалар яки ислах үткәрү идеясе тәкъдим ителә, ягъни әлеге ислахның төп максаты – зарарлы һәм дөрес булмаган гамәлләрне «төзәтү» һәм «яхшырту». Ислах динне тәҗдид кылу, ягъни яңарту, мөселманнар яшәеше өчен беренчел чыганаклар булган Коръән һәм

Сөннәткә нигезләнеп башкаруны күздә тота.

Россия империясендә яшәгән мөселманнар арасында дини яңарыш идеяләре XVII йөздә үк барлыкка килә, соңга таба XIX–XX гасыр башы мөселман галимнәре арасында киң тарала [Юзеев; Кемпер]. XIX гасырда, Идел–Урал регионында бай сәүдәгәрләр һәм сәнәгатьле мөселман буржуазиясе барлыкка килгәч [Салихов], аерым бер мөселман авторлары әсәрләрендә хакимият һәм җәмгыять тәнкыйтьләнә башлый. Ислам диненә карата күп кенә голямалар саклану позициясендә, ягъни руслардан чыккан яңарышларга карата сак булу ягында торалар. Русларга юнәлтелгән тәнкыйтьтән тыш, мөселман мәзһәбенең үзенең эчке кимчелекләре дә күрсәтелә, күп кенә бәхәсле темалар барлыкка килә. Мөселман галимнәре дини текстларны дөрес укуның заманга ярашлы яңа ысул һәм интерпретацияләрен тәкъдим итәләр.

Әлеге моназара-бәхәстә күренекле татар галиме, дин белгече һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) карашлары аерым бер урын били, хәтта кайбер замандашлары тарафыннан кискен тәнкыйтьләнә дә. Әлеге тәнкыйди карашлар аның 1870 елда Казанда «Нәзурәт әл-хак...» («Хакыйкатьне күзаллау») хезмәте басылып чykканнан соң аеруча көчәя. Кемпер фикеренчә, автор үзенең бу хезмәтендә киләчәк буын мөселманнары өчен ислам диненең башлангыч чоры кыйммәтләренә нигезләнгән идеал җәмгыять төзү проектын сурәтли [Кемпер, б. 615]. Бу образга туры килмәгән үзгәрешләр ялгыш дип табыла һәм кире кагыла. Мәрҗани мөселман җәмгыяте тормышын әлеге юл белән тәҗдид кылырга, ягъни яңартырга чакыра. Мисал рәвешендә ул ‘иша – төнге ястү намазы мәсьәләсенә аеруча басым ясап, аны иҗтиһад хокукын исбатлауда куллана. Хокук мәсьәләләре, «Нәзурәт әл-хак...» хезмәтеннән тыш, Мәрҗанинең башка әсәрләрендә дә урын ала, аларга Казанда 1889 елда дөнья күргән «Хикмәт әл-бәлигат» һәм 1883 елда басылган «Вафийәт әл-әсляф...» хезмәтләрен дә кертеп карарга мөмкин.

Мәрҗанинең әлеге реформаторлык карашлары барлык замандашлары тарафыннан да хупланмый, зур бер төркем голямалар аның фикерләренә каршы чыга. Мәсәлән, Мәрҗанинең оппоненты Габдулла ән-Нәсавиның 1874 елда Казанда басылган, «Нәзурәт әл-хак...» фикерләрен тәнкыйть итүгә корылган «Әл-Җәрудә» хезмәтен китерергә мөмкин. Габдулла ән-Нәсавидән тыш, Мәрҗанинең татар дөньясына Ишми хәзрәт исеме белән танылган төп идея дошманы Әбү-Нәкыйб Түнтәри (1842–1919), Ишми хәзрәт мәдрәсәсендә традицион мөселман белеме алган Мөхәммәт әш-Шауләнкари [әш-Шауләнкари, Тазкират, б. 66], Динмөхәммәт бине Ярмөхәммәт бине Мансур әт-Түнтәри (1849–1919), Гыйләҗетдин бине Мөхиддин әс-Сәрдәви әл-Казани кебек мөселман зыялылары җирле традицияләрне саклап калырга

тырышулары һәм Мәрҗани карашларына каршы чыгучылар буларак танылалар. Шунысы да игътибарга лаек: тикшеренүдә кулланылган барлык хезмәтләр дә турыдан-туры Мәрҗанинең «Нәзурәт әл-хак...» китабына каршы язылмаган, аларның кайберләре Мәрҗани һәм аның дәвамчыларының карашларын гомуми рәвештә тәнкыйть итүгә корылганнар.

### Хокук төшенчәләре

Мөселман хокукының нигезе бер-берсенә бәйле булган ике төп чыганактан гыйбарәт. Беренче чыганакны Коръән һәм Сөннәтнең хокукый яссылыктагы өйрәтмәләре тәшкир итә. Аның нигезендә мөселманнарның әхлакый һәм дини вөҗданы формалаша [Словарь..., 1991, с. 292]. Икенче төркем үз эченә рациональ чыганакларга нигезләнеп, беренче чиратта, иҗмаг, ягъни теге яки бу дини мәсьәләгә карата абруйлы мөселман голямаларының (мөҗтәһидләр һәм фәкыйһларның) уртак хөкеме, аларның кыяс ярдәмендә системалашкан мөселман хокукы доктринасы нормаларын эченә ала [Сюкияйнен]. *Иҗмаг* – абруйлы илаһият галимнәренең аерым бер мәсьәләгә карата килештерелгән уртак фикере, мөселман хокукының бер чыганагы [Словарь..., 1991, с. 91].

Мәгълүм булганча, иҗмагның барлыкка килүе VII гасырның икенче яртысындагы мөҗтәһидләр эшчәнлеге белән бәйле. Алар аерым бәхәсле мәсьәләләрне тикшерүнең билгеле бер тәртибен тәкъдим итәләр. Кыяс – тиңләштереп карау, охшашлыкка нигезләнеп фикер йөртү. Ул – әрра'й, ягъни мөстәкыйль фикер йөртүнең бер категориясе, хокук буенча рациональ эзләнүләрнең берсе булып тора. Кыяс Коръән текстларына, Сөннәткә (әл-кыяс әш-шәригый) яисә танылган һәм дәлилле фактка таяна (әл-кыяс әл-гакъли) [Словарь..., 1991, с. 137]. Икенче төркемнең нормалары соңрак, Коръән һәм Сөннәттә чагылыш тапмаган мәсьәләләр белән очрашканда, яисә әле яңа гына мөселман диненә күчкән кешеләрнең ислам тәгълиматы нигезендә тормышларын төзү очракларында барлыкка килә.

### Иҗтиһад

Мәрҗанинең оппонентлары аның «иҗтиһад капкаларын ачу»ына каршы чыга. Мөселман хокуклары доктринасы күп еллар дәвамында иректе иҗтиһад принцибына таянып үсеш ала. «Иҗтиһад» сүзе гәрәп теленнән «тырышу, эшкә күңел биреп эшләү, тырышлык – шаригать буенча, динне алга җибәрү максатыннан фәкыйһ, яисә ислам хокукы белгече тарафыннан барлык көчен юнәлдерү» буларак билгеләнә [Словарь, 1991, с. 91–92]. X–XI гасырларда хокук нормаларын тикшергәндә, иҗтиһадка мөнәсәбәт тә нык үзгәреш кичерә. Тора-бара ул Коръән һәм Сөннәткә таянып ирекле рәвештә хөкем чыгаруыннан туктап, төрле мөселман мәзһәбләре юнәлешен сайлау мөмкинлеге булып кына кала. Бу процесс «иҗтиһад капкалары ябылу» исеме белән йөртелә башлый. X гасыр башына (Һиҗридә IV гасыр) илаһият

галимнәре барлык мәсьәләләрне җентекле тикшереп, иҗмагта иҗтиһад капкаларын ябу карары чыгаралар. Әлеге консенсус күпчелек голямалар тарафыннан кабул ителсә дә, иҗтиһад хакында бәхәсләр вакыт-вакыт яңадан күтәрелеп тора. Бу исә, Вейл Халлак карашынча, фәкыйһларның әлеге хөкемне кабул итмәве буларак бәяләнә [Hallaq, 1984, p. 4]. Шулай ук дин белгеченең Коръән һәм Сөннәткә таянып иҗтиһад кылу өчен тиешле квалификациягә ия булу вакыты узу турында фикер урнаша. Әлеге вакыттан алып галим үз мәзһәбендә генә иҗтиһад кылырга тиеш була, бу иҗтиһад *тәхриҗ* дип аталып йөртелә башлый. Аны тормышка ашыру өчен катгый махсус билгеләнгән хокук нормалары барлыкка килә. Иҗтиһад чикләрен кысу нәтиҗәсендә, аның эчтәлеге дә үзгәрә, фәкыйһлар арасында доктрина тарафыннан күрсәтелгән тәкълид идеясе популярлашып китә [Hallaq, 1984, p. 4]. Мөҗтәһидләрнең дәрәҗәләре арту белән бергә, илаһият галимнәре арасында иҗтиһад кыла алучыларның саны кими төшә, аларның күпчелеге мөкаллид, ягъни традиция тарафдарлары *(каллада, таклид)* гына булып калалар дигән фикер мөселманнар арасында киң таралыш ала [шунда ук, б. 29].

Идел–Урал төбәгендәге тәкълид белән иҗтиһадны чагыштырып, М. Кемпер түбәндәге фикергә килә: тәкълид аерым метод буларак кабул ителми, ул иҗтиһад кебек динамик процессны тәшкил итә, төрле категорияләрдән гыйбарәт, һәм нинди дә булса актуаль бәхәстә үзең теләгән карашларны нигезләүдә ярдәм итә [Кемпер, с. 413–418]. Иҗтиһад һәм тәкълид тарафдарлары үткәннәргә мөрәҗәгать итеп, үз чорларын тәнкыйтьләп чыгалар. Әлеге төшенчәләрнең икесе дә үзгәрүчән чынбарлыкка карата яңа караш һәм аерым дини мәсьәләләрне Коръән һәм Сөннәткә таянып чишү юлларын тәкъдим итәләр. Шул сәбәпле исламны яңа тормыш шартларына яраклаштыру яисә яңа шартларны аңа туры китерү бары тәкълид яисә иҗтиһад белән башкарылырга мөмкин дип санала. Мәрҗани үзенең «Нәзурат әл-хак» әсәрендә, Коръән, Сөннәт дәлилләренә, иҗмаг, дүрт төп мәзһәб һәм башка күренекле фәкыйһлар карашларына таянып, гыйбадәт кылу мәсьәләсендә иҗтиһад итүнең барлык мөэминнәр өчен фарыз булуын, мәҗбүрилеген исбат итә. Бу очракта Мәрҗанинең иҗтиһад терминына нинди мәгънә салуын һәм нәрсәгә кабат әйләнеп кайтырга чакыруын истә тотарга кирәк.

Мәрҗани иҗтиһадны Коръән һәм Сөннәт буенча гыйбадәт кылуның *(иҗтиһад мотлака)* мөэминнәр өчен фарыз булуын һәм Кыямәт көненә кадәр сузылуын дәлилли [Мәрҗани, 2012, б. 105, 133]. Аның оппонентлары, киресенчә, Коръән һәм Сөннәткә нисбәтле иҗтиһадның тәмам булуы ягында торалар. «Җәрудә» авторы исә моңа дәлил буларак, иҗтиһад капкаларының ябылуы хакында «бөек голямаларның» сүзләрен китерә, аларның алга таба «гыйбадәт кылучының мөҗтәһид сүзләренә таянып эш

итәргә тиешлеге мәсьәләсендә фикъһе галимнәренең бер сүздә булуы» [ән-Нәсави, б. 27] турында уртак фикергә килүен, ягъни тәкълидне алга сөрүләрен искәртә.

Иҗтиһад кылуның вакыты турында Мәрҗани позициясе традицион буларак кабул ителә. Мәрҗани түбәндәгечә яза: «Әгәр дә Коръән һәм Сөннәткә яисә иҗмагка теге яисә бу сорау турыдан-туры кагылмаса, кыяс аркылы иҗтиһадка мөрәҗәгать итү тиештер». Әгәр Коръәндә, Сөннәттә, иҗмагта билгеле һәм кабул ителгән *(мутаватир)* дәлил булмаса иҗтиһад рөхсәт ителә [Мәрҗани, 2012, б. 97]. Мәрҗани фикеренчә, иҗтиһад кирәкле мәгълүмат булмаса, китерелгән дәлилләр йомшаграк яисә текст мәгънәви яктан бик нык җаенке булган очракта үткәрелергә мөмкин.

Бәхәсләрнең төп сәбәбе булып хокук төшенчәләрен төрлечә аңлау тора. ән-Нәсави, мәсәлән, хокук төшенчәләренә Коръән, Хәдис (Сөннәт), риваять, төгәл һәм кабул ителгән кыясны (ягъни иҗтиһад аркылы кыяс итүне) кертеп карый [Габдулла ән-Нәсави, б. 27]. Шул рәвешле абруйлы илаһият галимнәренең күпчелеге тарафыннан иҗтиһад хокук чыганагы буларак кабул ителә, ягъни тәкълидка алып баручы һәм һичшиксез үтәлүне күз алдында тотучы кагыйдә була.

Мәрҗани өчен, хокук чыганагы буларак Коръән, Сөннәт, иҗмаг һәм кыяс кабул ителә [Мәрҗани, 2012, б. 94]. Мәрҗани иҗмагка Пәйгамбәр сәхабәләренең сүзләрен дә кертеп карый, икенче төрле әйткәндә, бу «беренче дәрәҗәдәге иҗмаг» [шунда ук, б. 99–100]. Оппонентларыннан аермалы буларак, кыяс аркылы иҗтиһадны Мәрҗани гамәли мәсьәләләрдә генә фараз дип саный [шунда ук, б. 4]. Коръән, Сөннәт, сәхабәләр иҗмагында күрсәтелмәгән мәсьәләләрне тикшерү – иҗтиһадның төп кулланылу өлкәсе буларак күзаллана. Иҗтиһад Коръән һәм Сөннәттә чагылыш тапмаган, иҗтимагта каралмаган һәм сәхабәләр тарафыннан тикшерелмәгән, ягъни төгәл дәллиләре булмаган мәсьәләләрдән тора.

Иҗтиһадны төгәл һәм дәлилле белемгә кертү теге яисә бу хөкемнең дөрес булуы, шулай ук ялгыш иҗтиһад мәсьәләсен китереп чыгара. Ш. Мәрҗани әйтүенчә, иҗтиһад кеше аңының бары фаразга гына нигезләнгән хакыйкать белеме була, бары Аллаһ тарафыннан иңдерелгән хакыйкать кенә чын дөрес санала. Шул рәвешле, дөрес һәм дәлилле иҗтиһад була алмаган кебек, иҗтиһадта хаклылар һәм хаксызлар да булмый, бер генә кеше икенчесенә аның хаксызлыгын исбатлый алмый. Мәрҗани иҗтиһад кылуны шәхси җаваплылыкка кайтарып калдыра. Иҗтиһад бары фараз буларак кына билгеләнә, иҗтиһад кылгандагы төрле ялгышлыклар кичерелә һәм җәзасыз кала [шунда ук, б. 84]. Дөрес иҗтиһад кылган очракта кеше икеләтә, ялгыш иҗтиһад өчен бер генә тапкыр бүләкләнә. Ялгыш җибәрү гөнаһ буларак саналмый, мөэминнең иҗтиһадны танымавы, ягъни аның хәтта иҗтиһадта дөрес хөкем чыгарырга омтылыш

ясамавы исә зур гөнаһ санала. Мәрҗанинең оппонентлары исә, киресенчә, хата, ялгышлык җибәрү иҗтиһад яшенә җиткән мөҗтәһидкә генә гөнаһ саналмый дигән караштa була. Гадәти кешеләрнең, иҗтиһад яшенә җитмичә торып, ялгыш иҗтиһад кылуы гөнаһ буларак кабул ителә һәм җәзага тартыла [Габдулла ән-Насәви, б. 27–28].

### Иҗтиһад итүнең һәр мөэмин өчен мәҗбүри булуы. Мөҗтәһид

Теге яисә бу дини мәсьәлә буенча хокукый чыганакларда төгәл норма яки конкрет текст күрсәтелмәгән очракта иҗтиһад кылучы кеше *мөҗтәһид* дип атала. Мөҗтәһит иҗтиһад һәм истинбат кыла, ягъни Коръән һәм Сөннәттән, иҗмагтан кыяс, истихсан, мәсалих һәм башка хокукый ысулларлар ярдәмендә дәлилләр китерә. Мөселман сәясихокук теориясе буенча мөселман дәүләтендә хокукый мәсьәләләр мөҗтәһидләр вазифасы, ягъни дин һәм шәригать мәсьәләләрендә җаваплар эзләү үтә абруйлы һәм белемле кешеләрнең эше санала [Сюкияйнен].

«Нәзурәт әл-хакк» һәм «Хикмәт әл-бәлигат» әсәрләрендә Мәрҗани, иҗтиһад капкалары ачык икәнелеген раслаудан тыш, һәр кешегә, үзенең белеменнән чыгып иҗтиһад кылу фарыз, дип яза. Мәрҗани карашынча, иҗтиһад итү дәрәҗәсенә ирешкән барлык кешеләргә дә тәкълидкә таяну рөхсәт ителми [Мәрҗани, 2012, б. 101]. Кешенең аң-фикер сәләтеннән чыгып, Мәрҗани иҗтиһад итүнең беренчә төрен аера. Коръән, Сөннәт һәм иҗмагны яхшы белгән галимнәр, Мөхәммәт пәйгамбәрнең беренче өч буын дәвамчылары саваплы иҗтиһад кылырга – абсолют иҗтиһадка бара алалар, ягъни беренчел чыганакларга таяналар; башкалар исә мәзһәб (үз дини-хокукый юнәлешләре) эчендә генә иҗтиһад кылырга мөмкиннәр [Мәрҗани, 2012, б. 105, 133; 2008, б. 356]. Иҗтиһадка сәләтсез кешеләргә, «бер шаригать канунын икечесеннән аермаучыларга» исә абруйлы, үзе сайлап алган мөҗтәһид тәкълиденә таяну фарыз була [Мәрҗани, 2008, б. 356]. Ул шулай ук үзең сайлап алган теләсә нинди мөҗтәһидкә тулысынча ышанып бетмәү ягында булырга кирәк дип саный. Барыннан да элек, дөрес булган хөкемне өйрәнеп кабул итүнең түбәндәге таләпләре аерыла: 1. Сайланылган мөҗтәһид сирәк ялгышырга һәм һәрвакыт хакыйкатьне генә сөйләргә тиеш; 2. Дин һәм белем ягыннан танылган булырга тиеш.

Күренекле һәм абруйга лаек мөҗтәһид юлы белән барган кешеләр һәр очракта да аның хөкеменә таянырга һәм аңа охшарга тырышырга тиеш түгелләр. Галим фикеренчә, яңа мәсьәлә килеп чыкканда, шул мәсьәләгә мөнәсәбәттә иҗтиһад кылу (эшли алсалар) зарур [Мәрҗани, 2012, б. 102]. Голямалар уртак фикергә килә алмаган мәсьәлә буенча, мөҗтәһид сайлаганда, иярүче – мөкаллид ихтийат кылырга, ягъни аеруча сак эш итәргә тиеш. Шикле булган очракларда, әйтик, күңел болгану, кан китү вакытларында (хатын-кызлар тәһарәт

бозылмады дип уйласалар да) тәһарәтне яңарту, су булмаса ком белән һәр намаз өчен тәһарәтләнү кирәк [Мәрҗани, 2012, б. 101].

Мәрҗанинең оппоненты әт-Түнтәри, һәр кешегә иҗтиһад кылуның мөмкинлеген тәнкыйтьләп, түбәндәгечә яза: «Мәрҗани олуг шәехләрне кара халык (*гавам*) дәрәҗәсенә төшерә, шәригатьнең абруйлы белгечләрен аерым, гади кешеләр белән тигезли» [ат-Тунтари, 1909, б. 18]. Әл-Казани фикеренчә, «...гади халык дин мәсьәләренә кысылырага тиеш түгел [әл-Казани, 1899, с. 38], гади халык исламны кабул итеп гыйбадәт кылырга тиеш. Фән галимнәр өчен калсын» [шунда ук, с. 21].

«Җәрудә» авторы Мәрҗанинең Коръән, Сөннәт, иҗмаг, кыяска таяну ягында булуы белән килешсә дә, (аның фикеренчә) «һәр кеше үзлегеннән хөкем һәм нәтиҗәләр чыгарырга тиеш түгел» [Габдулла ән-Насави, б. 46]. Автор «Коръән һәм Сөннәткә нигезләнеп иҗтиһадны гади кешеләргә кылу рөхсәт ителүен алсак, безнең көннәрдә бу мөмкин түгел. Иҗтиһадның барлык кешегә рөхсәт булуы коткы гына тарата. Кешеләр Аллаһ өйрәтмәләре белән уйный башлый һәм галимнәргә каршы чыгарга мөмкиннәр» [шунда ук, б. 25]. Бу очракта «шәригатькә зур куркыныч яный. Шунлыктан динне саклап калу өчен гади кешеләргә иҗтиһад капкалары ябык булырга һәм мөҗтәһидләр өчен генә рөхсәт ителергә тиеш» [шунда ук, б. 25–26].

Ән-Насави иҗтиһадның белемле галимнәр (*хасса*) өчен рөхсәт ителүе хакында язса да, һәрвакыт диярлек голямаларга иҗтиһад кылырга комачау итүче сәбәпләр табылып тора. Мөҗтәһид аерым бер таләпләргә туры килергә тиеш була.

Беренчедән, ул ихсан[1] дәрәҗәсенә җитәргә тиеш. Аллаһы Тәгалә «мөэминнәрнең йөрәкләрен ачып, исламны кабул итәргә һәм ихсан дәрәҗәсенә күтәрелергә ярдәм иткән. Алар арасыннан мөҗтәһидләрне аерып чыгарган һәм аларга сорауларга дөрес җаваплар табарга булышкан. Бу кешеләр аның өйрәтмәләренә таянып хөкем чыгара алалар» [шунда ук, б. 3]. Икенчедән, алар яхшыны яманнан аерырлык итеп гарәп телен әйбәт белергә тиеш. Өченчедән, беренчел чыганаклар булган Коръән, Сөннәт һәм аларның контекстын яхшы үзләштергән булырга тиеш [шунда ук, б. 41–42]. Әгәр бу таләпләргә туры килсә, дүртенче – чикләүче шарт барлыкка килә. «Безнең заманда кайбер талантлы кешеләр изге текстларны әйбәтләп анализлый беләләр, әмма бу алар үзләре иҗтиһад кыла алалар дигән сүз түгел, ул алай гына җиңел башкарылмый» [шунда ук, б. 48]. Бишенчедән, замандашларның иҗтиһадка рөхсәтләре булмау: «Без, мөкаллидләр буларак, Коръән һәм Сөннәткә турыдан-туры таянырга тиеш түгелбез. Без

[1] әл-Ихсан («игелекле», «эчкерсез» ) – Коръәндә әл-ихсан эчкерсез һәм дөрес гыйбадәт кылу төшенчәсе буларак кулланыла һәм икейөзлелеккә, рияга каршы куела.

мөҗтәһидләр сүзенә таянырга тиеш» [шунда ук, б. 36]. Алтынчыдан, барлык мөҗтәһидләрнең үлеп бетүе һәм яңаларының булмавы. «Олуг илаһият галимнәре иҗтиһадның мөҗтәһидләр вафаты белән тәмамлануын искәртәләр, бу очракта безгә ни эшләргә, безнең дәвер иҗтиһад заманыннан тагын да ераграк бит» [шунда ук, б. 50].

Шул рәвешле Мәрҗани тиеш дип тапкан әйберләрне аның оппонентлары кабул итми. Мәрҗани «мөҗтәһид» категориясен аңлауның чикләрен киңәйтә. Мөҗтәһидләр рәтенә, хасса вәкилләреннән тыш, гади кешеләрдән булган барлык мөэминнәрне дә кертеп карый. Аерым мәсьәлә буенча хөкем чыгарган барлык кеше мөҗтәһид дип игълан ителә. Оппонентлары, киресенчә, бары беренчел чыганаклар булган Коръән һәм Сөннәткә таянып хөкем чыгарган кеше генә мөҗтәһид була ала, дип саныйлар.

## Иҗмаг

Тәкълид, Коръән һәм Сөннәттән тыш, илаһият галимнәре тарафыннан уртак килештерелгән хөкемнәр иҗмаг принципларына нигезләнә. Иҗмагның төп функциясе булып абруйлылык мәсьәләсен ачыклау тора. Исламда, Христиан динендәге кебек, дин әһелләренең катгый һәм рәсми иерархиясе булмаганлыктан, текстларның авторитетын һәм канунилыгын раслауны, аларга нигезләнеп кабул ителгән хөкемнәрнең дөреслеген үз өстенә алган аерым бер аппарат булдыру ихтыяҗы туа. Бу аппарат кабул ителгән хөкемнәрнең легитимлыгы өчен җавап бирергә тиеш була. Нәтиҗәдә, барлык мөселманнарны берләштерүче җәмгыять үзе үк шушы вазифаны үти башлый. [Hourani, 1964, p. 16]. Мөселман дөньясының аерымланып торган, географик яктан ерак урнашкан төбәкләрендә (мәсәлән, Идел буенда), әлеге бәхәс аеруча көчәя. Р. Мөхәммәтшин фикеренчә, иҗмаг фикъһе гыйлеменең нигезен тәшкил итә һәм әлеге гыйлемнең сыгылмалылыгын һәм төбәкләр арасындагы дини аермалыкларны канунлаштырырга ярдәм итә [Мухаметшин].

Җәмгыяви консенсус мөселманнарның догматик, хокукый һәм тарихи яшәешен формалаштыра. Барлык вакыйгалар яшәп килүче тәкълиди традиция нигезендә аңлатыла. Шул ук вакытта, иҗмаг нигезендә туган аерым бер хөкемне үтәүмәү әлеге җәмгыятьнең абруен шик астына куя. Мәгълүм булганча, ул чорда Идел буе мөселаннары Урта Азия тәкълиденә таянып эш итә. Шуңа күрә Мәрҗанинең мөселман дөньясында аерым бер «олуг галимнәр»не һәм аларның идеяләрен тәнкыйть утына тотуы Идел буе мөселман җәмгыятендә нык тамыр җәйгән бу традициянең нигезләрен какшата. Дж. Хаурани фикеренчә, иҗмаг оешканнан соң кыяс ярдәмендә иҗтиһад кылу кими төшә, аның урынына истихсан[1] һәм башка дәлилләр китерелә башлый.

[1] Истихсан – Әбү Хәнифә керткән хокукый мәсьәләләрне чишү алымы: кыяска нигезләнгән карардан бигрәк конкрет шартларга туры килүче хөкемне сайлау; фикһның икенче дәрәҗәдәге чыганагы.

Шул рәвешле, әлеге консенсусның карары кире кагылмыйча һәм кичекмәстән үтәлергә тиеш була. [Hourani, 1964, p. 24]. Бу позиция консенсусның Сөннәткә һәм Пәйгамбәр күрсәткән туры юлга таянуы белән аңлатыла. Әлеге фикер, бер яктан, традициянең эчтәлегенә «сакраль» мәгънә салып аның статусын ныгытса, икенче яктан, чикләре катгый билгеләнгән үсеш юнәлешен һәм доктринасын формалаштыруга ярдәм итә. Шул рәвешле, мөҗтәһиднең эшчәнлеге, элеккеге чорларда авторитетлы голямалар тарафыннан кабул ителгән хөкемнәрне үзгәртә алмавы белән бергә, соңгы чорларда туган бәхәсле мәсьәләләргә мөнәсәбәттә иҗмаг билгеләгән тәртипләрдән һәм кысалардан чыга алмавы белән дә чикләнә.

Исламда «консенсусның авторитетлыгы» мәсьәләсе берничә тапкыр күтәрелә. Гадәттә, иҗмагны тәнкыйтьләүчеләргә каршы җавап рәвешендә Пәйгамбәрнең «Минем өммәтем хаталанырга риза түгел» дигән сүзләре китерелә. Иҗмагның һич тә шик астына куелмый торган дөрес хөкем булуын әл-Могътазили, әш-Шафигый кебек дини авторитетлар да яклап чыга. Әш-Шафигый дәлилләре нигезендә консенсус барлык хокукчылар тарафыннан хокук чыганагы буларак раслана. XIX йөздә ислам реформалары барышында әлеге тема яңадан көнүзәк мәсьәләгә әверелә. Консенсусның чыганак буларак кыйммәте һәм абруйлылыгы проблемасы күтәрелә. Әлеге процесс, бөтен ислам дөньясына таралу белән бергә, Россия мөселманнарын да читләтеп узмый. Ул чорда тәнкыйтькә тартырлык нинди үзгәрешләр барлыкка килде һәм моның сәбәбе нәрсәдә булды соң? XIX йөз галимнәре иҗмагның дөреслегенә каршы чыкмыйлар. Консенсус инде исламга кадәрге җәмгыятьтә үк кулланылган һәм ул ислам тәгълиматының аерылгысыз өлеше булып тора. XIX гасыр галимнәре аның чикләрен дөрес билгеләми [Hourani, 1964, p. 13–26].

Мәрҗани өчен дә консенсус абруйлы хокук чыганагы булып тора. Мәсәлән, ул «Гади халык консенсусы буенча, Аллаһ тарафыннан күрсәтелгән, аның Китабында һәм Аның Илчесе хәдисләрендә билгеләнгәннәр барысы да фарыз һәм важиб һәм алар һичшиксез үтәлергә тиеш, җиңел карап эш итү тыела...» дип яза [Мәрҗани, 2008, б. 336].

Мәрҗани, үз оппонентларыннан аермалы буларак, Мөхәммәд пәйгамбәр дәвамчылары иҗмагын гына кабул итә, алардан соңгы галимнәр консенсусы аның өчен кыйммәткә ия булмый. Шул рәвешле ул хәнәфи мәзһәбендәге Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәхабәләре, аның дәвамчылары һәм җирле мөҗтәһидләр консенсусын үз эченә алган иҗмаг традициясе чикләрен төгәлрәк билгеләргә омтыла [Словарь, 1991, c. 91]. Болардан Мәрҗани Урта Азия мөҗтәһидләренең һәм җирле галимнәр консенсусын кире кага.

Мәрҗанинең иҗмаг чикләрен билгеләү хакындагы карашлары аның оппонентлары тарафыннан кискен тәнкыйть ителә. Мәсәлән, Динмөхәммәт

«әлеге рәфидит гомуми килешүне шик астны куя» дип язып чыга [ат-Тунтари, 1909, с. 28]. Динмөхәммәт шулай ук «ислам шәригате билгеләгән законнардан башка безгә башкалары кирәкми. Фәкыйһ һәм сәләфләр әлеге шәригать кануннарын аңлату өчен күп көч түккәннәр, әгәр дә без җәдид кыла башласак барыбыз да, һичшиксез, туры юлдан тайпылачакбыз» – дип фикер йөртә [шунда ук, б. 24]. Ән-Нәсави Мәрҗани эшчәнлеге бары «үз ихтыяҗы һәм максатыттан чыгып мөселман чыгынакларын фаш итәргә генә омтыла, моннан да гайре ни булырга мөмкин?» дип билгели [Габдулла ән-Насави, б. 5].

## Йомгак

Тикшеренү нәтиҗәсендә, XIX гасырда Идел буе мөселманнары акыл ияләренең традицион җәмгыятьнең яңарышын төрлечә кабул итүләре ачыкланды. Бу уңайдан Яңа заманда барлыкка килгән төшенчәләрне кабат тикшереп чыгу ихтыяҗы туа. Яңа тәҗрибә традициянең күрсәтмәләре һәм категорияләре аркылы өйрәнелә, аны яшәп килгән тәртипләргә яраклаштыру мөмкинлеге бирелә. Мөселман хокукы буенча чыганаклар һәм алардагы идеяләр яңа шартларга нисбәтле яңадан каралырга, өйрәнелергә тиеш булалар. Мәрҗани тәкъдим иткән әлеге реформа программасы (ислах) «иҗтиһад», «мөҗтәһид», «кыяс» һ.б. төшенчәләрне кабат тикшеренү объекты итүне күздә тота. Әлеге мәкаләдә без Мәрҗани һәм аның оппонентларының «иҗтиһад», «мөҗтәһид», «иҗмаг» кебек төшенчәләрне ничек кабул итүләрен өйрәндек.

Идел буе мөселман голямаларының иҗтиһад капкалары ябылу турындагы карашларын инкяр итеп, Мәрҗани иҗтиһад капкалары һәрвакыт ачык икәнлеген һәм Кыямәт көненә кадәр һәр кешегә иҗтиһад кылуның фарызлыгын исбатларга омтыла. Барлык мөэминнәр иҗтиһад кылырга тиеш булудан чыгып, Мәрҗани мөҗтәһид сүзенә салынган мәгънәне дә киңәйтеп бирә. Ул мөҗтәһидләр голямалардан гына түгел, гади халык арасыннан да була ала, дигән фикердә тора. Коръән, Сөннәт һәм сәхабәләрнең консенсусы булган иҗмагтан кала, кабул ителгән барлык хокукый хөкемнәр иҗтиһад чыганагы булырга тиеш дигән фикерне яклый. Иҗтиһад хокукының чыганакларын киңәйтеп, Мәрҗани үз оппонентлары карашлары белән килешмәгәнлеген күрсәтә. Галимнең иҗтиһад һәм мөҗтәһид билгеләмәләре үз заманы таләпләренә тулысынча туры килә. Нәтиҗәдә бу караш кеше ирегенең чикләрен киңәйтә, модернизация һәм урбанизация шартларында яңа инсан формалаштыру ихтыяҗын китереп чыгара.

Мәрҗанинең фикерләренә каршы булучылар «ул иҗмагны дөрес тәгъбир итми» дип саныйлар. Чынлыкта да, Мәрҗани иҗмагның авторитеты, аның һәр очракта да хакыйкатькә туры килүе мәсьәләсен күтәреп чыга. Шул ук вакытта ислам чыганагы буларак, ул иҗмагны кабул итә, әмма аны таррак мәгънәдә күзаллый. Галим беренчел дәрәҗәдә-

ге иҗмагны, ягъни Пәйгамбәр дәвамчылары иҗмагын гына кабул итеп, аннан соңгы буын иҗмагы үз кыйммәтен югалта, дип саный. Галим иҗмаг, иҗтиһад, кыяс мәсьәләләрендә җирле һәм Урта Азия галимнәренең хөкемнәре белән килешми.

Иҗмаг мөселман җәмгыяте өчен беренчел чыганак саналганга, Мәрҗани, иң әүвәл, Идел буе мөселманнары өчен Урта Азия голямаларының ни дәрәҗәдә авторитле булулары мәсьәләсен күтәрә, алар чыгарган хөкемнәрне шик астына куя. Безнең уебызча, Мәрҗанинең фикер-карашлары һәм тәкъдимнәре Идел буе мөселман җәмгыятенең үз мөстәкыйль хокукый һәм дини традициясен формалаштыруга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*әл-Казани, Гиладжуддин ибн Мухиддин ас-Сардави.* Нусул ал-хадида фи хыляфи ал-усул ал-джадида («Стальной клинок против новой методики»), (1899). Казань: Иман. рус. перевод.

*Мәрҗани Ш.* Нәзурат ал-хак фи фәрдийәт әл-гашаи вә ин ләм йагаб әшшәфәкъ («Эңгер-меңгер төшүгә бәйсез рәвештә кичке намазның кирәклеге турында хакыйкатькә бер караш»), 1870 елда басыла / Истанбул: Дар-ул-хикме, 2012, гарәп тексты.

*Мәрҗани Ш.* Хикмәт әл-балигат әл-җәннияти фи шәрх әл-гакаид әл-хәнәфияти («Хәнәфиләрнең дини ышанулары турында өлгереп җиткән дөрес карашлар китабы») / гарәп теленнән Д. Шаһавиев тәрҗемәсе. Казань, 2008.

*ат-Тунтари, Абу Накиб (Ишми ишан).* «ал-Ишарат ал-Ламига фи анмузадж ал-фикх ва гавамид ал-Кахстани» («Ясные указания по вопросам фикха и загадкам ал-Кахстани») (1899). Казань: Иман, рус. перевод.

*ат-Тунтари, Динмухаммад ибн Ярмухаммад ибн Мансур.* «Побуждение достойных ученых мужей к борьбе против неучей, искажающих чистое учение шариата» (1909). Казань: Иман, рус. перевод.

*аш-Шаулянкари, Мухаммад ибн Наджиб ибн мулла Биляль ибн дамулла Мазфар.* Тазкират ар-рашид бирадди кайди («Напоминание праведного о кознях завистника») (1901). Казань: Иман, рус. перевод.

*аш-Шаулянкари, Мухаммад ибн Наджиб ибн мулла Биляль ибн дамулла Мазфар.* (Ответ на трактат второго завистника) (1901). Казань: Иман, рус. перевод.

*Габудллаән-Нәсави.* Мөзһир әл-кәлимәт әл-җаруда әл-ләти хийа фи-нназура («Назурадәге куркыныч сүздәрне фаш итү»), 1874 елда басылып чыккан / Гарәп теленнән Р. Адыгамов тәрҗемәсе. Казань: изд. Иман.

*Атнашев Т., Велижев М.*«Contextisking»: Джон Покок – историк политических языков / Новое литературное обозрение №134 (4/2015), http://www.nlobooks.ru/node/6426 (дата доступа 20.05.2018)

*Идиятуллина Г.* Духовно-религиозная атмосфера в Поволжье в XVII–XVIII вв.

Ислам: Энциклопедический словарь. М.; Наука. Главная редакция восточной литературы, 1991

*Кемпер М.* Суфии и ученые в Татарстане и Башкортостане [1789–1889]: Исламский дискурс под русским господством: пер с нем. Казань: Российский исламский университет, 2008.

*Мухамметшин Р.* Мусульманская община как источник и цитадель татарского традиционализма / Татарские мусульманские приходы в Российской империи. Материалы Всероссийской научно-практической конференции (27–28 сентября 2005 г., г. Казань). Казань: Институт истории АН РТ, 2006. 308 с.

*«Понятия о России»:* К исторической семантике имперского периода: в 2-х томах. Новое литературное обозрение, 2012. Т.м 1. 576 с.; Т. 2. 496 с.

*Салихов Р.Р.* Участие татарского предпринимательства России в общественно-политических процессах второй половины XIX– начала XX в. – Казань: Фэн, 2004. 260 с.

*Сюкияйнен Л.Р.* Мусульманское право. М.: Наука, 1986. Использована электронная версия – http://www.gumer.info/bogoslov_Buks/Islam/Syk_Pravo/index.php (дата доступа 20.05.2018).

*Скиннер Кв.* The State / Пер. с англ. Д. Федотенко // Понятие государства в четырех языках / под ред. О. Хархордина. СПб., 2002. С. 12–74

*Словарь* основных исторических понятий: Избранные статьи в 2-х т. / пер. с немецкого К. Левинсон; сост. Ю. Зарецкий, К. Левинсон, И. Ширле; научн. ред. перевода Ю. Арнаутова. М., 2014

*Шагавиев Д.А*. Роль Шигабутдин Марджани в развитии татарской богословской мысли XIX века: дис. ... канд. ист. наук. Казань, 2010

*Юзеев А.Н.*Татарская религиозно-реформаторская мысль. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012.

*Hallaq W.B.* Authority, continuity, and change in Islamic law. Cambridge University Press, 2004.

*Hallaq W.B.* Was the Gate of ijtihad closed? // International Journal of Middle East Studies, Vol. 16, No. 1 (Mar., 1984), pp. 3–41.

*Hourani A.* Arabic Thought in the Liberal Age, 1798–1939. Cambridge University Press, 1983.

*Hourani G.* The *Basis of Authority of Consensus* in Sunnite *Islam* // Studia Islamica, No. 21 (1964), pp. 13–60.

*Sartori P.* Exploring the Islamic Juridical Field in the Russian Empire: An Introduction // Islamic Law and Society, 2017, № 24, pp. 1–19.

*Watt M.* Islamic philosophy and theology. Edinburg University Press, 1985

*Тикшеренү Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең №16-105-цГ/2018 гранты кысаларында башкарылды*

***Мәрданова Динара Зәмир кызы,***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының фәнни хезмәткәре*